**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләрен резервка калдыру турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт резерв җир фонды Уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләрен резервка калдыру турында» 2004 елның 22 гыйнварындагы ПУ-26 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 11 октябрендәге ПУ-872 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) 4 пунктына, икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Мирзакриев Рөстәм Рәүф улын Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт резерв җир фондының Попечительләр советы рәисе итеп билгеләргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 13 июнь
№ ПУ-332